КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 декабрь г.Казань № 1403

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Әйләнештәге акчаны тулыландыру максатларында 2022 елда сәнәгать үсеше фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү максатларында фондның эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә (докапитализацияләүгә) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» 1990 елның 2 декабрендәге 395-1 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредит оешмалары белән төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен компенсацияләүгә грантлар рәвешендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 14 июнь, 555 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Әйләнештәге акчаны тулыландыру максатларында 2022 елда сәнәгать үсеше фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме

күрсәтү максатларында фондның эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә (докапитализацияләүгә) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» 1990 елның 2 декабрендәге 395-1 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредит оешмалары белән төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен компенсацияләүгә грантлар рәвешендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 14 июнь, 555 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 август, 830 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә «грантлар» сүзендә кадәр «заемнар, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «грантлар» сүзендә кадәр «заемнар, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Әйләнештәге акчаны тулыландыру максатларында 2022 елда сәнәгать үсеше фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү максатларында фондның эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә (докапитализацияләүгә) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» 1990 елның 2 декабрендәге 395-1 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредит оешмалары белән төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен компенсацияләүгә грантлар рәвешендә субсидияләр бирү тәртибендә:

исемдә «грантлар» сүзендә кадәр «заемнар, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның беренче абзацында «грантлар» сүзендә кадәр «заемнар, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктта «грантлар» сүзендә кадәр «заемнар, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бурычларны кире кайтарганда алынган акчалар, алар буенча процентлар, һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган штрафлар һәм пенялар рәвешендәге башка керемнәр Фонд тарафыннан «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы һәм Фонд Уставы нигезендә сәнәгать субъектларына финанс ярдәме күрсәтү максатларына гына кулланыла.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 эш көнендә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.10 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

3.2 пунктның «в» пунктчасында «теркәү» сүзен «исәпкә кую» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

«б» пунктчасында «яисә сәүдә эшчәнлеге» сүзләрен өстәргә;

«г» һәм «д» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«г) түләүләрне кичектерү каралган яисә түләү сроклары җитмәгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр;

д) сәнәгать субъектының җитештерү яисә сәүдә эшчәнлегендә катнашмаган биналарны һәм җиһазларны арендалау, җиһазлар сатып алу һәм аларга сервис хезмәте күрсәтү;»;

«е» пунктчасында «һәм башка бүләкләү, шулай ук факторинг шартнамәләре буенча йөкләмәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

«з» пунктчасында «җитештерү» сүзеннән соң «яисә сәүдә» сүзләрен өстәргә;

«к» пунктчасына «, башка кредит оешмаларында ачылган заемщикның исәп-хисап счетларын тулыландырудан тыш, чит ил тәэмин итүчеләре белән исәп-хисаплар (шул исәптән чит ил валютасында) биш эш көне дәвамында исәпләүләр, заемщикның хезмәт хакы түләүдән тыш;» сүзләрен өстәргә;

3.4 пунктта:

беренче абзацта «бирү» сүзләренә кадәр «шулай ук заемнар» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эшчәнлегенең төп төре Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы сәнәгать субъектларына Фонд тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин